КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 21 май г.Казань № б-1019

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 5 октябрь, б-2182 нче боерыгына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 22 декабрь, б-3032 нче; 2025 ел, 11 февраль, б-249 нчы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада татар текстында «җитештерүне үстерү максатларында» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасында «Пилотсыз авиация системалары» илкүләм проектын гамәлгә ашыру буенча хөкүмәт ведомствоара комиссиясен төзергә һәм аның составын (боерыкка теркәлә) расларга» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 1 һәм 2 пунктлар өстәргә:

«1. Татарстан Республикасында «Пилотсыз авиация системалары» илкүләм проектын гамәлгә ашыру буенча хөкүмәт ведомствоара комиссиясен төзергә.

2. Бу боерыкка теркәлгән Татарстан Республикасында «Пилотсыз авиация системалары» илкүләм проектын гамәлгә ашыру буенча хөкүмәт ведомствоара комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын расларга.»;

Татарстан Республикасында «Пилотсыз авиация системалары» илкүләм проектын гамәлгә ашыру буенча хөкүмәт ведомствоара комиссиясе турындагы нигезләмәне (боерыкка теркәлә) расларга.

әлеге боерык белән расланган составны яңа редакциядә (боерыкка теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 5 октябрь, б-2182 нче
боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 21 май, б-1019 нчы
боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасында «Пилотсыз авиация системалары» илкүләм проектын гамәлгә ашыру буенча хөкүмәт ведомствоара комиссиясе турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасында «Пилотсыз авиация системалары» илкүләм проектын гамәлгә ашыру буенча хөкүмәт ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) – Татарстан Республикасында пилотсыз авиация системаларын үстерү тармагында, шул исәптән фәнни, фәнни-техник һәм инновацион эшчәнлек өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен эшләү һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләүне һәм тармак бергәлеге вәкилләре белән хезмәттәшлекне гамәлгә ашыручы даими эшләүче орган.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Стратегик үсеш һәм илкүләм проектлар советы һәм аның президиумы карарларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Комиссия үз эшчәнлеген федераль башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек итеп гамәлгә ашыра.

4. Комиссиянең төп бурычы – пилотсыз авиация системаларын үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру һәм шул исәптән түбәндәгеләр белән бәйле бурычларны хәл итү буенча килештерелгән тәкъдимнәр әзерләү:

транспорт системасы һәм икътисадның башка секторлары белән үзара бәйләнештә пилотсыз авиация системалары кулланышын үстерү белән;

пилотсыз авиация системаларын, аларны хокукка каршы кулланудан саклау чараларын эшләүне, җитештерүне, сертификацияләүне һәм эксплуатацияләүне оештыру белән;

пилотсыз авиация системаларын һава киңлегенә интеграцияләнүне тәэмин итү белән;

юридик һәм физик затлар өчен пилотсыз авиация системаларын куллану өлкәсендә хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү белән;

пилотсыз авиация системаларын җитештерү һәм куллану өлкәсендә дәүләти-хосусый партнерлык механизмнарын камилләштерү белән;

пилотсыз авиация системаларын җитештерү һәм куллану өлкәсендә эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырганда нигезләнмәгән чикләүләрне киметү белән;

пилотсыз авиация системаларын эксплуатацияләү өчен кирәкле инфраструктураны үстерү белән;

пилотсыз авиация системаларын эшләү, җитештерү һәм эксплуатацияләү өлкәсендә белгечләр әзерләү һәм мондый белгечләрнең квалификация дәрәҗәсен контрольдә тоту белән;

пилотсыз һава судноларын бердәм һава киңлегенә интеграцияләү белән;

Татарстан Республикасында пилотсыз авиация системаларын үстерү буенча бердәм дәүләт сәясәтен билгеләү белән;

юридик һәм физик затларга мәгълүмат бирү, аң-белем бирү һәм аларны җәлеп итү белән;

икътисадның мөстәкыйль тармагы буларак пилотсыз авиация үсеше өчен шартлар тудыру, шул исәптән пилотсыз авиация системалары базарын булдыруны һәм үстерүне һәм пилотсыз авиация системалары ярдәмендә авиация эшләрен башкаруны тәэмин итә торган Россия технологияләре комплексын булдыру юлы белән шартлар тудыру белән;

пилотсыз авиация техникасын уйлап табучыларны, җитештерүчеләрне, аның эксплуатантларын стимуллаштыру һәм аларга ярдәм күрсәтү белән, пилотсыз авиация системаларын һәм аларның элементларын эшләү, җитештерү һәм эксплуатацияләү өлкәсендә лицензияләү, сертификацияләү, нормалаштыру һәм стандартлаштыру буенча дәүләт системасы алымнарын һәм принципларын эшләү белән;

пилотсыз авиация системаларын эксплуатацияләү һәм аларны хокукка каршы куллanudан саклау куркынычсызлыгын арттыру белән;

һава киңлеген, аэродром, логистика инфраструктурасын файдалану нәтиҗәлелеген арттыру белән.

5. Үзенә йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру өчен Комиссия түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыра:

Татарстан Республикасында пилотсыз авиация системаларын җитештерүне үстерүгә һәм куллануга комплекслы анализ ясауны, аларның алга таба үсеше буенча төп чикләүләрне һәм юнәлешләрне билгеләүне тәэмин итә;

тармак бергәлеге белән берлектә, пилотсыз авиация системаларын үстерү буенча республика концепцияләрен, үсеш стратегияләрен, программаларны һәм гамәлләр планнарын эшләүне тәэмин итә;

Татарстан Республикасында пилотсыз авиация системалары тармагына инвестицияләр җәлеп итү, шул исәптән турыдан-туры җәлеп итү механизмнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәрне карап тикшерә;

пилотсыз авиация системаларын эксплуатацияләү өлкәсендә хезмәт күрсәтүләрнең конкурентлыкка сәләтен стимуллаштыру буенча республика механизмнарын билгеләү турында тәкъдимнәр әзерли;

һава транспортының республика инфраструктурасын үстерү һәм интеграцияләнгән структуралар төзү буенча тәкъдимнәр әзерли;

пилотсыз авиация системаларын эшләү, җитештерү, сертификацияләү һәм эксплуатацияләү өлкәсендә республика тариф һәм бәя сәясәте мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрне карап тикшерә;

финанс институтлары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру буенча, шул исәптән лизингка ярдәм күрсәтү механизмнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәрне карап тикшерә;

фән, технологияләр һәм техника үсеше стратегияләрен һәм аларның өстенлекле юнәлешләрен, инновацион эшчәнлекне, шул исәптән фән казанышларына нигезләнгән продукция һәм хезмәт күрсәтүләр базарының инновацион инфраструктурасын билгеләү буенча тәкъдимнәрне, шулай ук Татарстан Республикасында пилотсыз авиация системаларын үстерү өлкәсендә аларны реформалаштыру буенча тәкъдимнәрне карап тикшерә;

Татарстан Республикасында пилотсыз авиация системалары өлкәсендә югары технологияле производстволарны һәм хезмәт күрсәтүләрне үстерү буенча тәкъдимнәрне карап тикшерә;

Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык механизмнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

пилотсыз авиация системаларын үстерүгә йогынты ясый торган федераль һәм республика максатчан программалары үтәлеше барышы турында материалларны карап тикшерә, шулай ук Татарстан Республикасында аларны гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр әзерли;

һөнәри белем бирүне камилләштерү буенча, шул исәптән Татарстан Республикасының урта һөнәри һәм югары белем бирү системасында фәнни һәм инженерлык-техник кадрлар әзерләүне координацияләү буенча тәкъдимнәрне карап тикшерә;

пилотсыз авиация системаларын үстерү өлкәсендә Татарстан Республикасының халыкара хезмәттәшлеге мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрне карап тикшерә;

Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча норматив-хокукый базаны камилләштерү турында тәкъдимнәр әзерли;

кирәк булганда, Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча кирәкле материалларны Татарстан Республикасы дәүләт органнарыннан, бүтән республика башкарма хакимият органнарыннан, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан билгеләнгән тәртиптә соратып ала;

кирәк булганда, Комиссиянең билгеләнгән компетенциясе нигезендә Татарстан Республикасы законнары һәм башка хокукый актлар проектлары буенча каршылыклы фикерләрне карап тикшерә;

кирәк булганда, кызыксынучы республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, фәнни, мәгариф, иҗтимагый һәм башка оешмалар вәкилләрен Комиссия эшенә билгеләнгән тәртиптә җәлеп итә;

кадрлар әзерләүне оештыру кысаларында эксперименталь карарлар куллану буенча тәкъдимнәр әзерли;

кирәк булганда, Комиссия компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча планнарны хуплый һәм раслый;

пилотсыз авиация үсешенең еллык максатчан күрсәткечләрен билгеләү буенча, шул исәптән үз илебездә җитештерелгән пилотсыз авиация системаларын сертификацияләү һәм чыгару күләме, аларга төп комплектлау әйберләре, мондый системалар һәм эшләнмәләр җитештерүне локальләштерү дәрәҗәсе буенча тәкъдимнәр әзерли;

Татарстан Республикасында «Пилотсыз авиация системалары» илкүләм проектын гамәлгә ашыру чараларын финанслау күләмнәре һәм чыганаклары буенча тәкъдимнәр әзерли.

6. Комиссия эшчәнлеге кысаларында үз компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча Комиссия тарафыннан кабул ителә торган социаль-икътисадый нәтиҗәләрне анализлау өчен, республика башкарма хакимият органнары вәкилләрен, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, эшкуарлык җәмгыяте вәкилләрен, галимнәрне һәм бәйсез экспертларны җәлеп итеп, эшче төркемнәр төзелергә мөмкин.

7. Комиссия аның рәисе, рәис урынбасарлары, секретаре һәм әгъзалары составында төзелә.

8. Комиссия составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

9. Комиссия утырышларын әзерләүне һәм уздыруны оештыру Комиссия рәисе кушуы буенча Комиссия секретаре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

10. Комиссия утырышлары кирәк булуга карап, кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Комиссиянең чираттан тыш утырышлары Комиссия рәисе карары буенча үткәрелә.

11. Комиссия утырышын Комиссия рәисе йә аның кушуы буенча Комиссия рәисе урынбасарларыннан берсе үткәрә.

Комиссия әгъзалары утырышларда алмаштыру хокукыннан башка катнаша. Әгәр Комиссия әгъзасы утырышта катнаша алмаса, ул карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә алдан ук (утырышка кадәр) тапшырырга хокуклы.

Комиссия утырышына Комиссия составына керми торган республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, фәнни, мәгариф һәм башка оешмалар вәкилләре чакырылырга мөмкин.

12. Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашса, тулы хокуклы дип санала.

Комиссия карарлары утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

13. Комиссия рәисе тарафыннан Комиссия әгъзаларының читтән торып тавыш бирүне уздыру турында карар кабул ителергә мөмкин.

Читтән торып тавыш бирүне уздыру турында карар кабул ителгәндә Комиссия әгъзаларына, читтән торып тавыш бирүгә тәкъдим ителгән мәсьәлә буенча фикерләрне язма рәвештә җиткерергә мөмкин булган срок күрсәтелеп, бу хакта хәбәр ителә.

Читтән торып тавыш бирүне уздырганда карарлар тавыш бирүдә катнашучы Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Шул ук вакытта читтән торып тавыш бирүдә катнашучы Комиссия әгъзалары саны Комиссия әгъзаларының гомуми санының яртысыннан күбрәге булырга тиеш.

14. Комиссия утырышларында кабул ителгән карарлар Комиссиянең рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

15. Комиссия карарлары республика башкарма хакимият органнары өчен мәҗбүри булып тора.

16. Комиссия карарларының үтәлешен контрольдә тоту Комиссия секретаре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

17. Комиссия эшчәнлеген мәгълүмати-аналитик тәэмин итү Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы тарафыннан карап тикшерелә торган мәсьәләләргә җавап бирү өлкәләре нигезендә тәэмин ителә.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 5 октябрь, б-2182 нче
боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 21 май, б-1019 нчы
боерыгы редакциясендә)

Татарстан Республикасында «Пилотсыз авиация системалары» илкүләм проектын гамәлгә ашыру буенча хөкүмәт ведомствоара комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, комиссия рәисе |
| Коробченко Олег Владимирович | «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры, комиссия рәисе урынбасары |
| Шәйхетдинов Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Фәсхиев Герман Николаевич | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының сәнәгать бүлеге башлыгы, комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Әбҗәлилова Ләйсән Рәхим кызы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе вице-президенты |
| Әһлиуллин Фәнил Әнвәр улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры |
| Айзатуллин Марат Мансур улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Вәлиев Ленар Наил улы | «Эйдос-Медицина» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Вандюков Дмитрий Владимирович | «Иннополис университеты» югары белем бирү автоном коммерциягә карамаган оешмасы директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Гарипов Илнур Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенең беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Дикопольский Георгий Валерьевич | «Татарстан Республикасының Дроннар (пилотсыз һава суднолары) ярышлары федерациясе» төбәк физкультура-спорт иҗтимагый оешмасы директоры (килешү буенча) |
| Драгунов Игорь Сергеевич | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгының кризиска каршы идарә итү буенча урынбасары (килешү буенча) |
| Җиһаншин Азат Илдус улы | Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры |
| Җәббаров Марат Азат улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| Кадыйров Азат Рифгать улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры |
| Карпов Родион Михайлович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрының беренче урынбасары |
| Киреев Назир Талип улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры киңәшчесе |
| Колчин Иван Петрович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Кузюров Равил Әфраим улы | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры |
| Леонов Владимир Александрович | Татарстан Республикасы спорт министры |

| | |
|---|---|
| Малышев Владимир Николаевич | «Аэрокон» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча) |
| Миңнеханов Рәсүл Рифкать улы | «Саклау һәм оборона мәнфәгатьләрендә төрле билгеләнештәге чишелешләргә ярдәм компетенциясе үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Миңнеханов Рифкать Нургали улы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе президенты |
| Мөҗипов Рәмис Гаптрәис улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары |
| Нәфыйгин Альберт Илдар улы | Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Нигъмәтуллин Марат Илгиз улы | «Тулпар Техник» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Охоткин Кирилл Германович | «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техника университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Павлов Рөстәм Реннатович | В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең бизнеска хезмәт күрсәтү үзәге директоры (килешү буенча) |
| Побежимов Валерий Николаевич | «Эникс» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Сафин Ленар Ринат улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Снитко Артем Александрович | «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте генераль директорының корпоратив мәсьәләләр буенча урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Фәрахов Илдар Рәмзил улы | «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе директоры урынбасары – мәгълүмат технологияләрен үстерү идарәсе башлыгы |
| Һадиуллин Илсур Гәрәй улы | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Хәнифов Фәрит Мөдәррис улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Хисаметдинов Марат Нәгыйм улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары |
| Шакиров Марат Хәйдәр улы | «Унипарк» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Шацких Павел Александрович | «Казан «Электроприбор» заводы» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Шивков Игорь Николаевич | «Авиачишелешләр тәҗрибә-конструкторлык бюросы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Яковлев Альберт Валерьевич | Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары |
| Якупов Эльвир Тафил улы | «А.Н.Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техника университеты – КАИ» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең стратегик үсеш һәм икътисад буенча проректоры (килешү буенча). |

---